Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXVI-3**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 ноябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендәге муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы турында

Инвестицияләр җәлеп итү, яңа төр продукцияләр җитештерү, аеруча прогрессив булган технологияләр һәм җитештерүләр кертү, “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә өстәмә эш урыннары булдыру, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге 823 номерлы карары белән расланган “2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисади үсеше һәм инновацион икътисады” Дәүләт программасының “2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парклары һәм сәнәгать мәйданчыклары төзү һәм үстерү” ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” №131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә 1 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә җир кишәрлекләре чикләрендә гомуми мәйданы 53 448 кв.м. булган муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы төзергә (алга таба – Муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы).

2. Расларга:

2 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы турында Нигезләмәне;

3 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының Күзәтчелек советы турындагы Нигезләмәне;

4 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Күзәтчелек советы составын;

5 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Идарәчесе турындагы Нигезләмәне;

6 номерлы кушымтага ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Балык

Бистәсе муниципаль районы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеге алып бару турында Үрнәк килешүне.

3.“Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы территориясендәге муниципаль милектәге яки аларга карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен җирле бюджетка алыну өлешендәге аренда түләве буенча 2018 елның 1 декабреннән 2023 елның 1 декабренә чаклы түбәндәге күләмнәрдә ташламалар билгеләргә:

арендалауның беренче елында – аренда шартнамәсендә билгеләнгән еллык аренда түләве күләменең 20% ы;

арендалауның икенче елында – аренда шартнамәсендә билгеләнгән еллык аренда түләве күләменең 40% ы;

арендалауның өченче елында – аренда шартнамәсендә билгеләнгән еллык аренда түләве күләменең 60% ы;

арендалауның дүртенче елында – аренда шартнамәсендә билгеләнгән еллык аренда түләве күләменең 80% ы;

арендалауның бишенче елында һәм алга таба– аренда шартнамәсендә билгеләнгән еллык аренда түләве күләменең 100% ын

юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең түбәндәге категорияләре өчен:

-муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы Идарәчесе;

-“Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы территориясендә үзенең җитештерү эшчәнлеген яисә корылмалар, продукция җитештерү объектлары төзү буенча эшләрен гамәлгә ашыручы резидентлар.

4.Әлеге карарның 3 пункты нигезендә җир кишәрлекләре өчен аренда түләүләре буенча ташламалар куллануга нигез булып җир кишәрлекләре арендаторлары тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына тапшырылган түбәндәге документларның торуын билгеләргә:

муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе өчен – конкурс комиссиясенең муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы идарәчесен сайлап алу турындагы карары;

муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы резидентлары өчен – муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы территориясендә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген алып бару хакындагы килешүе һәм муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы резиденты сыйфатында теркәлү турында билгеләнгән формадагы таныклыгы.

5. Муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы эшчәнлеге кысаларында җир кишәрлекләрен файдаланмаучы әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләре арендаторларының җир кишәрлекләре өчен аренда түләвен тулы күләмдә кертүен билгеләргә.

6. Муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы территориясендә берничә җир кишәрлеген арендага алган әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләре арендаторларына бер җир кишәрлегенә карата гына ташлама бирелүен билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2014 елның 28 мартындагы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы төзү турында” XXXVI-10 номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

9. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-3 номерлы карарына
кушымта №1

**Муниципаль дәрәҗәдәге**
**“Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы чикләрендәге**
**җир кишәрлекләренең исемлеге**

| №п/п | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Мәйдан, кв.м. |
|---|---|---|
| 1 | 16:34:200114:149 | 51560 кв. м |
| 2 | 16:34:200114:152 | 1888 кв. м |
| **Барлыгы:** | | 53448 кв.м |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-3 номерлы карарына
кушымта №2

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районының**
**муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы турында**
**Нигезләмә**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль

дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы турындагы әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы төзү һәм эшләвенең хокукый нигезләре тәгаенләнә.

**1 маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы төзүнең максатлары**

Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территорияләрен, икътисадның эшкәртү тармакларын үстерү, яңа төр продукцияләр җитештерү, аеруча прогрессив булган технологияләр һәм җитештерүләр кертү максатларында төзелә.

**2 маддә. Төп терминнар һәм төшенчәләр**

Әлеге Нигезләмә максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр файдаланыла:

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы – бердәм оператор (идарәче компания) тарафыннан идарә ителүче, милекнең барлык формаларындагы күчемсез объектларның 20 мең кв.м дан ким булмаган мәйдан биләүче, эчендә яңа производстволар оештыру һәм үстерү өчен уңай шартлар тудырыла торган, гомуми чиге булган җир кишәрлегендә урнашкан территория ягыннан аерымланган комплекс;

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Резиденты – Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлеп, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында сәнәгать-җитештерү эшчәнлеге алып бару хакында үзләре белән килешү төзелгән индивидуаль эшмәкәр яки, унитар предприятиедән гайре, коммерция оешмасы;

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Идарәчесе – юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр, атап әйткәндә, идарәче компания яисә мәйданчыкның Резидентлар ассоциациясе, яисә, Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлеп, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы кооперациясе;

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының Күзәтчелек советы – муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын үстерү программасын тормышка ашыруның барышына контроль функцияләрен гамәлгә ашыручы коллегиаль фикер алышу органы.

**3маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзү шартлары**

3.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы муниципаль яисә хосусый милектәге җир кишәрлегендә яисә дәүләт милке буларак чикләнмәгән җир кишәрлегендә урнашырга мөмкин.

3.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы төзү моментына әлеге мәйданчыкны хасил итүче җир кишәрлекләрендә дәүләт, муниципаль, хосусый милектәге объектлар урнашкан булырга мөмкин.

3.3. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзү моментына әлеге мәйданчыкны хасил итүче җир кишәрлекләрендә мәйданчыкны төзү максатларына тәңгәл килә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен зарур булган инфраструктура объектлары урнашкан булуы ихтимал.

**4маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы төзү һәм бетерелүе**

4.1. Муниципаль яисә хосусый милектәге җир кишәрлегендә яисә дәүләт милке буларак чикләнмәгән җир кишәрлегендә урнашкан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының түбәндәге нигезләмәләрне эченә алган карары белән төзелә:

1) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының исеме;

2) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясенең чикләре;

3) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының эшләү үзенчәлекләрен билгеләүче бүтән мәгълүматлар.

4.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының булу срогы чикләнми.

4.3. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын бетерү фәкать Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзү турындагы карарында тәгаенләнгән эшчәнлек муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында аның резидентлары тарафыннан өч ел дәвамында алып барылмаган очракта гына рөхсәт ителә.

4.4. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын бетерү турында карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы тарафыннан кабул ителә.

4.5. Хосусый милектәге җир кишәрлегендә урнашкан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзү һәм бетерү турындагы карар җир кишәрлегенең милек хуҗасы тарафыннан кабул ителә.

**5маддә. .Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы белән идарә итү**

5.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы белән идарә итү муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесенә йөкләнә.

5.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе үткәрү тәртибе расланган конкурс йомгаклары буенча тәгаенләнә.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башкарма комитеты тарафыннан – муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы муниципаль милектәге җир кишәрлегендә яисә дәүләт милке буларак чикләнмәгән җир кишәрлегендә урнашкан очракта.

җир кишәрлегенең милек хуҗасы тарафыннан – муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы хосусый милектәге җир кишәрлегендә урнашкан очракта.

5.3. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе функцияләренә керә:

1) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары белән эшчәнлек алып бару турында килешү төзү һәм аның шартларын үтәү буенча контрольне гамәлгә ашыру;

2) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентларына проект документациясенә кирәкле экспертиза үтүдә, матди-техник тәэмин ителештә, персонал яллауда булышлык күрсәтү;

3) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы чикләрен үзгәртү турында тәкъдимнәр кертү;

4) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының эшләү нәтиҗәләре турында хисапларга анализ;

5) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә арендага бирелмәгән җир кишәрлекләренең булуы турында басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүматлар бастыру;

6) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары реестрын алып бару;

7) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының планировка проектын эшләү буенча заказ бирүче функцияләрен, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының инженерлык корылышы проектын тормышка ашыру буенча, шул исәптән транспорт инфраструктурасы, газ, электр, җылылык, су белән тәэмин итү, су чистарту һәм су бүлгеч системаларын һәм объектларын, инфраструктураның һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының коллектив файдаланудагы бүтән объектларын төзекләндерү буенча заказ бирүченең (төзүченең) функцияләрен гамәлгә ашыру;

8) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә урнашкан инфраструктура объектларын файдалану һәм тоту;

9) хезмәт күрсәтүләр, шул исәптән электр, җылылык, су белән тәэмин итү һәм су бүлү, уртак файдаланудагы территорияләрне санитар җыештыру, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территорияләрен саклау буенча, транспорт, мәгълүмати һәм бүтән хезмәт күрсәтүләр;

10) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентларына муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару өчен буш җир кишәрлекләре һәм (яки) биналарны файдалануга бирү һәм тиешле килешүләр төзү;

11) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башкарма комитетының вәкаләтле органына квартал саен үзенең эшчәнлеге һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты тарафыннан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешүне үтәве хакында хисап бирү.

### 6 маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзүне һәм үстерүне финанслау

Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзүне һәм үстерүне, шул исәптән һәрбер резидентның җитештерү, транспорт һәм бүтән инфраструктурасын, әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күздә тотылган инфраструктура объектларыннан гайре, финанслау муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы

резиденты средство лары һәм закон белән тыелмаган бүтән чыганаклар хисабына гамәлгә ашырыла.

## 7 маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының күзәтчелек советы

7.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында инвестиция проектларын тормышка ашыру барышына, муниципаль бюджет средстволарын сарыф итүгә, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесенә муниципаль ярдәм күрсәтүнең максатка ярашлылыгы турында бәяләмәләр хәзерләүгә, гомуми попечительлек функцияләрен тормышка ашыруга, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып баруга гаризаларны экспертлар бәяләвенә контроль булдыру максатларында муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының күзәтчелек советы төзелә.

7.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының күзәтчелек советы әгъзалары булып түбәндәгеләрнең вәкилләре торырга мөмкин:

1) территорияләрендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы урнашкан муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының;

2) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы милек хуҗасының;

3) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесенең;

4) тармак ассоциацияләренең (берлекләренең) һәм Татарстан Республикасы сәүдә-сәнәгать палатасының;

5) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының инвестицияләре күләме муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы эшчәнлегенә инвестицияләнгән (салынган, кертелгән) средстволарның гомуми күләменнән 10% ка артып киткән резидентларының.

7.3. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының күзәтчелек советы турында Нигезләмә һәм аның персональ составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән раслана.

## 8 маддә. Ярдәм итү формалары

8.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентларына Татарстан Республикасы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тиешле норматив актларында күздә тотылган формалар һәм шартларда инвестицион эшчәнлек булышлыгы күрсәтелә.

8.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесенә һәм резидентларына кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме күрсәтү буенча тормышка ашырыла торган программалары кысаларында финанс ярдәме алу, эшсез гражданнарга үзмәшгульлектә булышлык итү, авылда хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм күрсәтү һәм инновацион эшмәкәрлекнең кече формаларына булышу буенча түләүсез консультация хезмәтләре күрсәтә.

**9 маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру**

9.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген Россия Федерациясе законнары һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашыралар.

9.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентларының хокуклары тотрыклылыгын гарантиялиләр һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының эшләү срогы дәвамында аларның эшчәнлек шартларын начарайта алмыйлар.

9.3. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты статусына ия булмаган зат муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген законда каралган гомуми нигезләрдә гамәлгә ашырырга хокуклы.

**10 маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү**

10.1. .Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү буенча муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты килешүнең гамәлдә булу срогы дәвамында муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында килешүдә күздә тотылган эшчәнлекне гамәлгә ашырырга йөкләмә ала, шул исәптән килешүдә каралган күләмдә һәм срокларда инвестицияләр гамәлгә ашырырга, ә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентына әлеге Нигезләмә нигезендә ярдәм күрсәтүне тәэмин итүче статус бирергә йөкләмә ала, шул исәптән аның бизнес-планын тормышка ашыру өчен җир кишәрлекләре һәм җитештерү мәйданнары арендалау хокукы, шулай ук әлеге Нигезләмәдә күздә тотылган бүтән хокукларны бирергә.

10.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү буенча үзенең хокук һәм йөкләмәләрен бүтән затка тапшырырга хокукы юк.

10.3.Әгәр җир кишәрлеге муниципаль милектә яисә җир кишәрлегенә дәүләт милке чикләнмәгән булса, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешүнең үрнәк формасы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән раслана.

10.4. Хосусый милектәге җир кишәрлегендә урнашкан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешүнең формасы һәм шартлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җир кишәрлегенең милек хуҗасы тарафыннан билгеләнә.

**11маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү төзү өчен зарури документлар**

11.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты статусын алырга ниятләгән зат муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесенә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү төзүгә гариза тапшыра. Гаризада түбәндәгеләр булырга тиеш:

1)гариза бирүченең муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы тибына туры килүче уйлаган эшчәнлеге турында мәгълүматлар;

2) гариза бирүченең ниятләгән эшчәнлеге өчен зарур булган җир кишәрлегенең яки бинаның мәйданы турында мәгълүматлар;

3) уйланылган инвестицияләр хакында мәгълүматлар, шул исәптән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү төзелгән көннән алып бер ел дәвамындагы;

4) гариза бирүченең 2007 елның 24 июлендәге “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 209-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән шартларга ярашлы рәвештә кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты булып торуын раслаучы документлар;

5) гариза тапшыручы юридик затның яки индивидуаль эшмәкәрнең реквизитлары ( уставындагыча тулы атамасы, юридик һәм факттагы адресы, җитәкче турында мәгълүматлар, контакт телефоны, веб-сайт һәм электрон почта адреслары);

6) ниятләгән җитештерү, ахыргы нәтиҗәләр (товарлар) һәм җитештереләчәк продукциянең күләмнәре турында мәгълүмат;

7) эш урыннары турында мәгълүматлар;

8) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына гариза бирүченең түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләре буенча гариза бирү аеннан алдагы айның азагындагы хәл буенча үтәлмәгән йөкләмәләренең булмавын раслаучы салым органының билгеләнгән тәртиптә расланган белешмәсе.

11.2. Әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелгән документлар муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе тарафыннан опись буенча кабул ителә. Описьнең документларны кабул итү датасы билгеләнгән күчермәсен муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе гариза бирүчегә җибәрә (тапшыра).

11.3. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе әлеге маддәнең 11.1 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча түбәндәге карарларның кайсы да булса берсен кабул итә һәм гариза бирүчегә җибәрә:

1) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турындагы гаризаны экспертлар бәяләве өчен муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының күзәтчелек советы каравына кертү хакында;

2) документларны гариза бирүчегә кире кайтару һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының күзәтчелек советына кабул иткән карар турында хәбәр

итү хакында.

11.4. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе гариза бирүчегә документларын түбәндәге очракта кире кайтара:

1) әгәр әлеге маддәнең 11.1 пунктында күрсәтелгән документларны гариза бирүче тулы күләмдә тапшырмаса яисә тапшырылганг гаризада һәм (яки) документларда мәгълүмат тулы һәм (яки) дөрес булмаса;

2) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү төзүгә гаризада күрсәтелгән шартларга туры килә торган буш җир кишәрлекләре һәм (яки) бина булмаганда;

3)гариза бирүченең ниятләгән эшчәнлеге муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы төзү максатларына туры килмәгәндә.

11.5.Гаризаны экспертлар бәяләве нәтиҗәләре буенча муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының күзәтчелек советы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы идарәчесенә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында гариза бирүче белән килешү төзүнең максатка ярашлылыгы хакында бәяләмә бирә.

### 12 маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү төзү тәртибе

12.1. Күзәтчелек советы тарафыннан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында гариза бирүче белән килешү төзүнең максатка ярашлылыгы хакында карар кабул ителү датасыннан соң 10 эш көне эчендә идарәче гариза бирүче белән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешүне хәзерли һәм төзи.

12.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә.

### 13 маддә. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешүне өзү тәртибе

13.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты тарафыннан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү шартларын җитди бозу очрагында гамәлдән чыгарылырга мөмкин.

13.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты тарафыннан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешү шартларын җитди бозу булып тора:

1) инвестицияләрне муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешүдә күздә тотылган күләмдә һәм срокларда гамәлгә ашырмау;

2) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында

килешүдә күздә тотылмаган эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

3) сәнәгать мәйданчыгы идарәчесе таләбе буенча муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты эшчәнлеге турында кирәк булган мәгълүматны тапшырмау;

4) килешүдә күздә тотылган бүтән очракларда.

13.3. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешүне өзү очрагында зат муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты статусын җуя.

13.4. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты статусын җуйган зат муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гомуми нигезләрдә гамәлгә ашырырга хокуклы.

**14 маддә. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе**

Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзү яки аның бетерелүе белән, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары һәм идарәчесе тарафыннан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә тиешле эшчәнлекне алып бару шартларын бозу белән бәйле бәхәсләр, шулай ук әлеге Нигезләмә белән җайга салына торган мөнәсәбәтләрдән килеп туган бүтән бәхәсләр Россия Федерациясе законнарына нигезләнеп хәл ителә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-3 номерлы карарына
кушымта №3

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының Күзәтчелек советы турында Нигезләмә**

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге “Прикамье” сәнәгать мәйданчыгы турында”гы карары нигезендә эшләнде (алга таба – карар) һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Күзәтчелек советының статусын, составын, функцияләрен һәм вәкаләтләрен билгели, аны төзү, эш тәртибен һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының идарә органнары белән үзара бәйләнешен тәгаенли.

Әлеге Нигезләмәдә билгеләмәләре карарда бирелгән түбәндәге төшенчәләр файдаланыла:

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы (алга таба – МДСМ (ППМУ));

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының Күзәтчелек советы (алга таба – Күзәтчелек советы);

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Идарәчесе (алга таба –

Идарәче).

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Күзәтчелек советы Идарәче эшчәнлеген килештерүче һәм аңа контроль ясаучы орган буларак төзелә һәм әлеге Нигезләмә һәм гамәлдәге законнар нигезендә эш итә.

## 2. Күзәтчелек советының функцияләре

2.1.Күзәтчелек советының функциясе Идарәче эшчәнлеген килештерү һәм аңа контроль ясаудан гыйбарәт.

2.2.Күзәтчелек советы үзенең функцияләренә ярашлы рәвештә гамәлгә ашыра:

-МДСМ эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләүне;

-Идарәче тарафыннан тәкъдим ителгән МДСМ ның үсеш концепциясен карау һәм раслауны;

- МДСМ территориясендә эшчәнлек алып бару турында килешүләр төзүгә риза булмауга, шулай ук аларны өзү турындагыларына шикаятьләр карауны;

-Идарәченең ел саен бирелә торган хисапларын карауны;

- проектларга экспертиза үткәрүне.

## 3. Күзәтчелек советы составы

3.1.Күзәтчелек советы составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән раслана.

3.2. Күзәтчелек советына аның рәисе җитәкчелек итә.

3.3. Күзәтчелек советы составының әгъзалар саны 7 кешедән ким, 15 кешедән артык булырга тиеш түгел һәм гомуми саны так булырга тиеш.

3.4. Күзәтчелек советының сәркатибе:

3.4.1) рәис йөкләмәсе буенча Күзәтчелек советы утырышларын оештыру-техник яктан хәзерләүне гамәлгә ашыра;

3.4.2) Күзәтчелек советы утырышларының беркетмәләрен алып бара. Күзәтчелек советы утырышының беркетмәсе утырышны үткәргәннән соң 3 эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

3.4.3) Күзәтчелек советы утырышлары беркетмәләрен теркәүне алып бара;

3.4.4) мәгълүмати материалларны Күзәтчелек советы әгъзаларына һәм бүтән кызыксынучы затларга таратуны тәэмин итә;

3.4.5) Күзәтчелек советы кабул иткән карарларны кызыксынучы затлар игътибарына ирештерә;

3.4.6) Күзәтчелек советы рәисенең бүтән йөкләмәләрен үти;

3.4.7) Күзәтчелек советы рәисенә хисап тота.

3.5.Күзәтчелек советы әгъзалыгына түбәндәгеләрнең вәкилләре кертелергә мөмкин:

җирле үзидарә органнарының, казна һәм бюджет учреждениеләренең;

территорияләрендә МДСМ урнашкан авыл җирлекләре башлыкларының;

МДСМ милек хуҗасының;

МДСМ Идарәчесенең;

тармак ассоциацияләренең (берлекләренең) һәм Татарстан Республикасының сәүдә-сәнәгать палатасының;

инвестицияләре күләме МДСМ эшчәнлегенә кертелгән инвестиция средстволарының гомуми күләменнән 10% ка артык булган МДСМ резидентларының;

иҗтимагый һәм бүтән оешмаларның.

## 4. Күзәтчелек советының эш тәртибе

4.1. Күзәтчелек советы рәисе аның эшен оештыра, Күзәтчелек советы утырышларын чакыра һәм аларда рәислек итә.

4.2. Күзәтчелек советы рәис яки аның урынбасары тарафыннан зарурлык туганда чакырыла, ләкин кварталга бер мәртәбәдән сирәк түгел, шулай ук Күзәтчелек советы әгъзаларының өчтән икесеннән күбрәге инициативасы буенча. Бу вакытта Күзәтчелек советы утырышының көн тәртибе Күзәтчелек советы әгъзаларына утырыш планлаштырылган датага хәтле өч эш көне алдан таратыла.

4.3. Күзәтчелек советы утырышы анда әгъзаларның яртысыннан артыгы катнашканда булган дип санала.

4.4. Рәис карары буенча Күзәтчелек советы утырышларына бүтән затлар чакырылырга мөмкин.

Чакырылган затлар тавыш бирү хокукына ия түгел һәм алар утырышта үзләре чакырылган сораулар буенча гына фикер алышканда һәм карар кабул иткән чорда гына катнашалар, әгәр Күзәтчелек советы рәисе тарафыннан башкасы куелмаса.

4.5.Күзәтчелек советы карарларны гади күпчелек тавыш белән кабул итә.

Күзәтчелек советының һәрбер әгъзасы бер тавышка ия.

Күзәтчелек советының бер әгъзасының тавышын икенчегә тапшыру тыела. Тавышлар саны тигез булган очракта Күзәтчелек советы рәисенең тавышы хәлиткеч санала.

4.6.Күзәтчелек советы рәисе кирәк булганда Күзәтчелек советы әгъзалары саныннан һәм Идарәче вәкилләреннән МДСМ эшчәнлегенең конкрет мәсьәләләре буенча карарлар әзерләү өчен даими эш итүче һәм вакытлы эшче төркемнәр төзергә мөмкин.

4.7.Зарур очракларда Күзәтчелек советы Идарәчегә, шартнамә нигезендә тиешле белгечләрне җәлеп итеп, аерым мәсьәләләр буенча экспертизалар һәм консультацияләр оештыруны йөкли.

## 5. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Күзәтчелек советы әгъзаларының хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы

5.1. Күзәтчелек советы рәисе тәэмин итә:

5.1.1) Күзәтчелек советы эшен оештыруны;

5.1.2) Күзәтчелек советы утырышларын чакыруны һәм аларда рәислек итүне;

5.2. Күзәтчелек советы рәисе булмау очрагында аның функцияләрен урынбасарларының берсе гамәлгә ашыра.

5.3.Күзәтчелек советы әгъзалары хокуклы:

5.3.1)әлеге Нигезләмә һәм Күзәтчелек советы рәисе биргән ышанычнамәләрдә билгеләнгән чикләрдә Күзәтчелек советын башка оешмалар, предприятиеләр, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм учреждениеләре, гражданнар белән мөнәсәбәтләрдә тәкъдим итәргә;

5.3.2)Идарәче һәм МДСМ ның бүтән органнары эшчәнлеге белән бәйле мәгълүматны алырга.

5.4. Күзәтчелек советы әгъзалары тиеш:

5.4.1) үзенең бурычларына намус белән карарга;

5.4.2) МДСМ эшчәнлеге турында аларга билгеле булган конфиденциаль мәгълүматны таратмаска.

5.5. Күзәтчелек советы әгъзалары 2006 елның 27 июлендәге "Персональ мәгълүматлар турында" 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Күзәтчелек Советы эше барышында мәгълүм булган МДСМ эшчәнлеге хакындагы конфиденциаль хәбәрне үз эченә алган мәглүматларны таратмау өчен персональ җаваплылык тоталар.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-3 номерлы карарына
кушымта №4

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Күзәтчелек советы составы**

| | |
|---|---|
| Исланов<br>Роман Леонидович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Күзәтчелек советы рәисе |
| Токранов<br>Вячеслав Иванович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары,, Күзәтчелек советы рәисе урынбасары |
| Гатиятов<br>Дилүс Харисович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы, Күзәтчелек советы сәркатибе |
| Күзәтчелек советы<br>әгъзалары: | |

| | |
|---|---|
| Вафин Фәрит Мансурович | рәис урынбасары – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының бүлек башлыгы |
| Хәсәнов Рәүф Ногманович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге башлыгы |
| Ногманова Илсия Мәликовна | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Миндубаев Илдар Илдусович | Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы урынбасары |
| Дормидонтов Руслан Олегович | районның эшмәкәрләр берләшмәсе вәкиле (килештерү буенча) |

Территориясендә МДСМ урнашкан авыл җирлеге башлыгы (килештерү буенча)

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-3 номерлы карарына
кушымта №5

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы**
**Идарәчесе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Идарәчесе (алга таба – Идарәче) – ул Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә теркәлгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы белән идарә итүче юридик зат яки индивидуаль эшмәкәр, ягъни идарәче компания яисә мәйданчык Резидентлары Ассоциациясе яисә Авыл хуҗалыгы кооперативы.

1.2. Идарәче үткәрү тәртибе билгеләнә торган конкурс нәтиҗәләре буенча тәгаенләнә:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан – муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы

муниципаль милектәге җир кишәрлегендә яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлегендә урнашкан очракта;

җир кишәрлегенең милек хуҗасы тарафыннан – муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы хосусый милектәге җир кишәрлегендә урнашкан очракта.

1.3. Идарәче муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы төзү турындагы карар, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы турында Нигезләмә, әлеге Нигезләмә һәм гамәлдәге законнар нигезендә эш итә.

## 2. Идарәченең максаты һәм бурычлары

2.1. Идарәченең максаты һәм бурычлары булып тора:

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары эшчәнлеген килештерү;

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы эшчәнлеген тәэмин итү;

муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентларына кирәкле ярдәмне күрсәтү.

## 3. Идарәченең функцияләре

3.1. Идарәченең функцияләренә керә:

1) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары белән эшчәнлек алып бару турында килешү төзү һәм аның шартларының үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыру;

2) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентларына документация проектларына кирәкле экспертиза үтүдә, матди-техник тәэмин итүдә, персонал яллауда булышлык күрсәтү;

3) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы чикләрен үзгәртү турында тәкъдимнәр кертү;

4) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының эш итү нәтиҗәләре буенча хисапларын анализлау;

5) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә арендага бирелмәгән җир кишәрлекләренең булуы турында мәгълүматларны басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чараларында бастыру;

6) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентларының реестрын алып бару;

7) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының планировка проектын эшләү буенча, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының инженерлык корылышы проектын тормышка ашыру буенча заказ бирүченең (төзүченең), шул исәптән транспорт инфраструктурасы, газ, электр, җылылык, су белән тәэмин итү, су чистарту һәм су бүлү объектлары һәм системалары төзелеше, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендәге уртак кулланыштагы бүтән инфраструктура объектларын төзекләндерү буенча функцияләрен гамәлгә ашыру;

8) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә урнашкан инфраструктура объектларын файдалану һәм тоту;

9) хезмәт күрсәтүләр, шул исәптән энергия чыганакларына тоташтыру, уртак файдаланудагы территорияләрне санитар җыештыру, муниципаль дәрәҗәдәге

сәнәгать мәйданчыгы территорияләрен саклау буенча, транспорт, мәгълүмати һәм бүтән хезмәт күрсәтүләр;

10) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентларына эшчәнлек алып бару өчен буш җир кишәрлекләре һәм (яки) биналарны файдалануга бирү һәм тиешле килешүләр төзү;

11) муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының Күзәтчелек советы утырышларында квартал саен үзенең эшчәнлеге һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты тарафыннан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешүне үтәве хакында хисап бирү.

## 4. Шикаять бирү тәртибе

4.1.Идарәче һәм резидентлыкка дәгъва кылучылар яки муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары арасында бәхәсләр туганда мәсьәлә Күзәтчелек советы утырышына чыгарыла. Әгәр Күзәтчелек советы утырышында бәхәс җайланмаса, алга таба бәхәс Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә хәл ителә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2018 елның 19 ноябрендәге
XXXVI-3 номерлы карарына
кушымта №6

## Татарстан Республикасы
## Балык Бистәсе муниципаль районы
## муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә
## сәнәгать-җитештерү эшчәнлеге алып бару турында
## Үрнәк килешү

“__” _________ 20__ ел. № ______

Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы Идарәчесе (атамасы) _________________________________________________________________йөзендә,

*(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

________________________________________нигезендә эш йөртүче бер яктан

*( актның аталышы, номеры, датасы)*

һәм ________________________________________алга таба Резидент дип аталучы *(оешманың атамасы һәм оештыру-хокукый формасы*)

________________________________________________________________ йөзендә,

*(вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме)*

_________________________ ________________нигезендә эш йөртүче икенче яктан

*(актның аталышы, номеры, датасы)*

алга таба “Яклар” дип аталучы яклар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе

муниципаль районының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы (исеме) турында”гы карары нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр.

1.Килешү предметы

Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында Резидент тарафыннан әлеге Килешүгә теркәлә торган бизнес-план нигезендә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеге алып бару әлеге Килешү предметы булып тора, атап әйткәндә:

____________________________________________________________________.

*(муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгындагы сәнәгать-җитештерү эшчәнлегенең төре)*

2.Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1.Идарәче бурычлы:

2.1.1. Резидент белән сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен Резидентның тиңдәшле гаризасын алган датадан соң _________эш көненнән дә соңармыйча *(шул срокта)* муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы чикләрендә урнашкан һәм дәүләт кадастр исәпкә алуын үткән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе (субаренда шартнамәсе) төзергә.

Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең (субаренда шартнамәсенең) срогы әлеге Килешүнең гамәлдә булу срогыннан артык булырга тиеш түгел.

2.1.2.Әлеге Килешүне имзалаган датадан соң 3 (өч) эш көне эчендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары реестрына Резидентны теркәү турында язма кертергә.

2.1.3. Резидентка муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты сыйфатында теркәлүне раслаучы билгеләнгән тәртиптәге таныклык бирергә.

2.1.4.Инженер-техник тәэминат челтәрләренә тоташтыруның техник шартларын, төзелешкә рөхсәт, Россия Федерациясе законнары нигезендә объектны файдалануга кертүгә рөхсәт алырга һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы чикләрендә төзелеш яки реконструкцияне гамәлгә ашыручы Резидентка аларны Резидентның тиңдәшле гаризасын алган датадан соң _______эш көненнән дә соңармыйча *(шул срокта)* тапшырырга.

2.1.5.Резидентка муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары реестрыннан өземтәне Резидентның тиңдәшле язмача запросын алган датадан соң _________эш көненнән дә соңармыйча *(шул срокта)* бирергә.

2.1.6. Резидент тарафыннан әлеге Килешүне үтәүгә контрольне гамәлгә ашырырга.

2.1.7.Идарәченең Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган бүтән бурычлары да бар.

2.2.Идарәче хокуклы:

2.2.1. Резиденттан язмача запрослар нигезендә һәм муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы белән идарә итү функциясен башкару буенча үзенең вәкаләтләре кысаларында кирәкле мәгълүматны һәм документларны алырга.

2.2.2.Идарәченең Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган бүтән хокуклары да бар.

2.3.Резидент бурычлы:

2.3.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә фәкать әлеге Килешүдә каралган сәнәгать-җитештерү эшчәнлеге генә алып барырга.

2.3.2. Бизнес-планда каралган чараларны үтәү барышында инвестицияләр, шул исәптән түбәндәге этапларга туры китереп капитал салуларны гамәлгә ашырырга:

_______________________________________________________________________.

*(инвестицияләр сроклары һәм күләмнәре, шул исәптән капитал салулар,сумнарда)*

2.3.3. Әлеге Килешүне төзү датасыннан соң _________*(срок)* эш көненнән дә соңга калмыйча муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы чикләрендә урнашкан җир кишәрлеген арендага (субарендага) бирү турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп рәсмиләштерелгән гаризаны Идарәчегә җибәрергә.

2.3.4. Төзелешкә рөхсәт бирү турындагы Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп рәсмиләштерелгән гаризаны проектлар документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен алган көннән соң _________ *(срок)* эш көненнән дә соңга калмыйча Идарәчегә җибәрергә.

2.3.5. Резидентның Россия Федерациясе законнарында күздә тотылган бүтән бурычлары да бар.

2.4. Резидент хокуклы:

2.4.1. Язмача запрос нигезендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары реестрыннан өземтәләр алырга.

2.4.2. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты сыйфатында теркәлүне раслаучы билгеләнгән тәртиптәге таныклык алырга.

2.4.3. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында урнашкан милек хуҗасы хокукындагы күчемле һәм күчемсез мөлкәте белән Россия Федерациясе законнары нигезендә үзе теләгәнчә файдаланырга;

2.4.4. Резидентның Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән хокуклары да бар.

3.Килешүнең гамәлдә булу срогы

3.1. Әлеге Килешү _________(*срок)* кадәр срокка төзелә һәм Яклар кул куйган датадан үз көзенә керә.

3.2. Килешүнең гамәлдә булу срогы Якларның үзара ризалыгы белән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының эш итүе туктатылуга чаклы калган сроктан артып китмәгән срокка озайтылырга мөмкин.

4.Килешүне үзгәртү һәм өзү шартлары

4.1. Әлеге Килешү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы (исеме) турында"гы карарында күздә тотылган тәртиптә үзгәртелергә мөмкин. Әлеге Килешүгә кертелә торган үзгәртүләр әлеге Килешүгә өстәмә килешүләр белән рәсмиләштерелә.

4.2. Әлеге Килешүнең көче туктатыла:

4.2.1. Әлеге Килешү төзелгән срок тәмамлану белән.

4.2.2. Әлеге Килешүне өзгән очракта.

4.2.3. Әлеге Килешүдә каралган җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе (субаренда шартнамәсе) туктатылу очрагында, арендалау шартнамәсе (субаренда шартнамәсе) җир кишәрлеген сатып алу сәбәпле өзелү очракларыннан гайре.

4.2.4. Резидентны муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты статусыннан мәхрүм иткән очракта.

4.2.5. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгының эш итүе срогыннан алда туктатылган очракта.

4.3.Әлеге Килешү Якларның үзара килешенүе буенча өзелергә мөмкин.

4.4. Әлеге Килешү икенче Як тарафыннан әлеге Килешү шартларының җитди бозылуы сәбәпле бер Якның таләбе буенча суд тарафыннан, шартларның мөһим үзгәрүе нәтиҗәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы (исеме) турында”гы карарында күздә тотылган бүтән нигезләр буенча гамәлдән чыгарылырга мөмкин.

4.5. Әлеге Килешү буенча Якларның үзләренә алган йөкләмәләрен үтәгәндә җитди бозу булып тора:

4.5.1. инвестицияләрне муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турында килешүдә каралган күләмдә һәм срокларда гамәлгә ашырмау;

4.5.2. муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгында эшчәнлек алып бару турындагы килешүдә каралмаган эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

4.5.3. муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты эшчәнлеге турында сәнәгать мәйданчыгы Идарәчесе таләбе буенча кирәкле мәгълүматны тапшырмау;

4.5.4. килешүдә күздә тотылган башка очракларда.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар әлеге Килешү буенча йөкләмәләрен үтәмәгән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

5.2. Әлеге Килешүнең 4.5 пунктында күрсәтелгән шартларының Резидент тарафыннан җитди бозылуы сәбәпле әлеге Килешүне срогыннан алда туктатканда муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты статусын җуйган зат әлеге Килешүнең 2.3.2 пунктында каралган инвестицияләр (капитал салулар) суммасының, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резиденты статусын җуйган датага гамәлгә ашырылган инвестицияләр (капитал салулар) күләмен чигереп, 5 (биш) проценты күләмендә штраф түләргә тиеш.

5.3. Яклар әлеге Килешүдәге йөкләмәләрен җиңеп чыга алмаслык шартлар барлыкка килгән очракта үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителәләр.

5.4.Әлеге Килешү буенча җиңеп чыга алмаслык шартлар булып, Якларның теләк һәм ихтыярларына бәйсез рәвештә барлыкка килгән, Яклар алдан күрә һәм намуслы рәвештә эш итүче Яктан көтү максатка ярашлы һәм акланган чара һәм средстволар белән булдырмый кала алмаган теләсә нинди гадәттән тыш хәл тора. Мондый хәлләргә керә: хәрби хәрәкәтләр, кораллы низаглар, җәмәгатьчелек тәртипсезлекләре, террорчылык актлары, атом-төш, химик яки биологик агуланулар, эпидемияләр, табигать бәла-казалары, техноген һәлакәтләр, дәүләт хакимияте органнарының актлары һәм гамәлләре, әлеге Килешү буенча өченче затларның йөкләмәләрне Як тарафыннан үтәү срогын үтәп булмауга һәм (яки) җитди бозуга китерүче гамәлләре (мондый хәл-шартларның пәйда булуы Якларның берәрсе тарафыннан әлеге Килешүдәге йөкләмәләрен турыдан-туры бозуы нәтиҗәсендә килеп чыккан очраклардан гайре).

5.5. Җиңеп чыга алмаслык шартлар барлыкка килгәндә Як аларның барлыкка килү моментыннан соң 3 (өч) эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге хәл турында икенче Якка хәбәр итәргә бурычлы. Белдерү хәбәре хәлнең характеры турындагы мәгълүматларны, шулай ук бу хәлләрнең барлыгын раслаучы документларны да үз эченә алырга тиеш.

5.6. Як тарафыннан җиңеп чыга алмаслык шартлар барлыкка килү турында хәбәр алынган моменттан соң 30 (утыз) эш көне дәвамында Яклар җиңеп чыга алмаслык шартларның йогынтысын киметү өчен үзара ярдәм итешүнең аеруча нәтиҗәле тәртибен билгеләргә тиешләр, шулай ук әлеге Килешү шартларын үтәүнең аеруча кулай ысулларын.

5.7. Җиңеп чыга алмаслык көч шартлары Якка җитди комачаулык ясаса яисә барлык йөкләмәләрнең яки йөкләмәләренең мөһим өлешен үтәү срокларын әлеге Килешү буенча икенче Як тарафыннан җиңеп чыга алмаслык көч шартлары барлыкка килү турында белдерү хәбәре алган моменттан алып рәттән 180 (йөз сиксән ) көн дәвамында бозса, ул очракта Якларның һәркайсы әлеге Килешүнең гамәлдә булуын туктатуга кадәр 30 (утыз) көннән дә соңга калмыйча икенче Якка әлеге Килешүне өзү турында белдерү хәбәре җибәрергә хокуклы.

## 6. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

6.1. Муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгын төзү яки аның эш итүен туктату, муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы резидентлары һәм Идарәчесе тарафыннан муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы территориясендә тиешле эшчәнлек алып бару шартларының бозылуы белән бәйле бәхәсләр, шулай ук бүтән бәхәсләр Россия Федерациясе законнарын кулланып хәл ителә.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

7.1. Әлеге Килешү нигезендә резидент хокукларын һәм йөкләмәләрен икенче затка тапшырырга хокуклы түгел.

7.2. Резидент тарафыннан үзенең статусын җуюю һәм Килешүнең гамәлдә булуы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән нигезләр буенча туктатылган очракта Резидент тарафыннан төзелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать мәйданчыгы чикләрендәге җир кишәрлеген арендалау шартнамәсенең (субаренда шартнамәсенең) көче туктатыла.

7.3. Әлеге Килешү бер үк юридик көчкә ия булган һәр Як өчен берәр нөсхә итеп ике нөсхәдә төзелде.

7.4.Әлеге Килешүгә теркәләләр һәм аның аерып алынгысыз өлеше булып торалар:

7.4.1. Бизнес-план.

## 8. Якларның реквизитлары һәм имзалары

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Балык Бистәсе муниципаль<br>районының муниципаль<br>дәрәҗәдәге сәнәгать<br>мәйданчыгы Идарәчесе | Татарстан Республикасы<br>Балык Бистәсе муниципаль<br>районының муниципаль<br>дәрәҗәдәге сәнәгать<br>мәйданчыгы Резиденты |
| Адрес: ________________________<br>ИНН: __________________________<br>ОГРН: _________________________ | Адрес: ___________________________<br>ИНН: _____________________________<br>ОГРН: ____________________________ |
| _______________________________<br>(имза) | __________________________________<br>(имза) |